КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 2 июль г.Казань № 537

2020 – 2022 елларга «Мәгариф» илкүләм проектының «Цифрлы белем бирү мохите» федераль проекты кысаларында гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында цифрлы белем бирү мохитенең максатчан моделен кертү чараларын тормышка ашыру турында

Россия Федерациясе Президентының «2024 елга кадәрге чорга Россия Федерациясен үстерүнең илкүләм максатлары һәм стратегик бурычлары турында» 2018 елның 7 маендагы 204 номерлы Указын тормышка ашыру, Россия Федерациясен стратегик үстерүнең төп юнәлеше буенча проект комитеты утырышының 2018 елның 7 декабрендәге 3 номерлы беркетмәсе белән расланган «Цифрлы белем бирү мохите» федераль проектының, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында «Мәгариф» илкүләм проекты кысаларында төбәк проектлары паспортларын раслау турында» 2018 ел, 13 декабрь, 1131 нче карарының (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында «Мәгариф» илкүләм проекты кысаларында төбәк проектлары паспортларын раслау турында» 2018 ел, 13 декабрь, 1131 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 ел, 30 март, 254 нче карары редакциясендә) максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә (шул исәптән федераль проектның гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында цифрлы белем бирү мохитенең максатчан моделен кертү өчен матди-техник базаны яңарту өлешендә «Россия Федерациясенең барлык субъектларында гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында цифрлы белем бирү мохитенең максатчан моделе кертелде» дигән 1.4 нче нәтиҗәсенә) ирешү максатларында, шулай ук Татарстан Республикасы Хөкүмәте һәм «Талант һәм уңыш» белем бирү фонды арасында хезмәттәшлек итү турындагы 2019 елның 28 маендагы 20 номерлы килешү нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгын 2020 – 2022 елларга «Мәгариф» илкүләм проектының «Цифрлы белем бирү мохите» федераль проекты кысаларында гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында цифрлы белем бирү мохитенең максатчан моделен кертү чараларын тормышка ашыру буенча төбәк координаторы итеп билгеләргә.

2. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2020 – 2022 елларга цифрлы белем бирү мохитенең максатчан моделен кертү буенча чаралар комплексын («юл картасы»н);

Гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында оештырыла торган цифрлы белем бирү мохите тасвирламасын.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин